БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«14» 07 2023 ел № 190

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитетының «Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2023 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турындагы» 2023елның 31 мартындагы 127 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитетының «Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2023 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турындагы» 2023елның 31 мартындагы 127 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче пунктны 3нче пункт дип санарга;

1.2. 3 нче пунктны 4нче пункт дип санарга;

1.3. 2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килгән керем күләменең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2024 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь кыйммәтләрен кабул иткәнчегә кадәр,торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында гражданнарны аз керемлеләр дип тану өчен җаваплы вазыйфаи затларга (хезмәткәрләргә), һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитетының «Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2023 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турындагы» 2023елның 31 мартындагы 127 номерлы карарына таянып билгеләнгән чик күрсәткечләрен кулланырга. »

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов